Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

05.10.2022

Менделеевск ш.

№593

Менделеевск шәһәре территориясендә
җирләү эше мәсьәләләре буенча
махсуслаштырылган хезмәтне сайлап алуга
ачык конкурс уздыруга
конкурс комиссиясе
составын раслау турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Менделеевск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Җирләү һәм җирләү эше турында" 1996 елның 12 гыйнварендагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ритуаль хезмәтләр оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск шәһәре территориясендә җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәтне сайлап алуга ачык конкурс комиссиясе составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru / урнаштырырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырырга.

3.Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының «Менделеевск шәһәре территориясендә җирләү эше буенча махсуслаштырылган хезмәтне сайлап алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 31 августындагы 544 номерлы карарының 2 пункты үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары вазыйфасын башкаруга йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы С.В.Метальников

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царева

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
№______
1 номерлы кушымта

МеНДЕЛЕЕЕВСК ШӘҺӘРЕ ТЕРРИТОРИТОРИЯСЕНДӘ ҖИРЛӘҮ ЭШЕ БУЕНЧА МАХСУСЛАШТЫРЫЛГАН ХЕЗМӘТНЕ САЙЛАП АЛУГА КОНКУРС КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| Метальников С.В. | - | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы, Комиссия рәисе |
| Хорькова А.А. | - | Торак сәясәте, шәһәр хуҗалыгы һәм сәүдә бүлегенең баш белгече, Комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | | |
| Антоновская Н.И. | - | Менделеевск муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Мисько А.В. | - | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының сатып алулар бүлеге башлыгы |
| Искаков А.Ф. | | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| Хәбиров Р.З. | - | Баш архитектор хезмәте архитекторы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Инвестиция һәм инфраструктура үсеше идарәсе» МАУ |
| Царева Е.С. | - | Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы |